ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№166 от «06» 03 2024 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 9 августындагы 262 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Казан районара табигатьне саклау прокуратурасының 13.03.2024 елның 13 мартындагы 02-07-2024/Прдп218 протесты нигезендә, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1 "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын яңа редакциядә раслау турында" 2021 елның 9 августындагы 262 номерлы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган 2 нче кушымтадагы Җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут билгеләмичә, дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрдән яки җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына ( алга таба - административ регламент) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Административ регламентның 2.5.1 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) гариза бирүченең һәм гариза бирүче вәкиленең шәхесен раслаучы документ (КФҮ, Башкарма комитетка мөрәҗәгать иткәндә бирелә);»;

1.2. Административ регламентның 2.5.1 пунктының 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) территориянең кадастр планында кулланылачак җирләрнең яки җир участогы өлешләренең чикләре схемасы, территория чикләренең характерлы нокталарының координаталарын күрсәтеп, җир яки җир участогының бер өлешен куллану планлаштырылган очракта (күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрын алып барганда кулланыла торган координаталар системасын кулланып) (алга таба - чикләр схемасы).»;

1.3. Административ регламентның 2.8.2 пунктчың 3,4,8 пунктчаларын төшереп калдырырыга;

1.4. Административ регламентның 2.8.2 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 9,10, 11, 12, 13 пунктлары өстәргә:

0000012154

«9) объектларны планлаштырылган җир участогына урнаштыру рөхсәт ителгән куллану төренә ярашлы рәвештә аны куллану мөмкин булмауга китерә;

10) объектларны урнаштыру өчен планлаштырылган җир участогына карата вәкаләтле органга милекче хокукларын гамәлгә ашыру хокукы бирелмәгән яки дәүләт милке чикләнмәгән җир участоклары белән идарә итү вәкаләтләре бирелмәгән;

11) җир участогы аукцион предметы булып тора, аны үткәрү турында хәбәр итү Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 статьясының 19 пункты нигезендә урнаштырылган;

12) җир кишәрлегенә карата Россия Федерациясе Җир Кодексының 39.18 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан аның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлеге бирү турында хәбәр итү бастырылган һәм урнаштырылган;

13) исемлекнең 25 нче пунктында күрсәтелгән объектны урнаштыру урыны төзелешкә рөхсәт таләп ителмәгән велосипедлар, роликлар, самокатлар һәм башка спорт инвентарын прокатлау пунктларын урнаштыру схемасында, һәм әлеге Тәртипнең 3 пунктының дүртенче абзацында күрсәтелгән велопарковкаларны прокат пунктларын урнаштыру схемасы каралмаган.»;

1.5. Административ регламентның 3.6.2.1. пунктында икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Рөхсәт бирү турында яисә рөхсәт бирүдән баш тарту турындагы карар гариза кергән көннән алып 25 көн эчендә һәм күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң 3 эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә заказлы хат белән, аларга тапшырылган документларны кушып җибәрелә.»;

1.6. Административ регламентның 5.2 пунктына түбәндәге эчтәлектәге абзаө өстәргә:

«Объектларны урнаштыруга рөхсәт бирүдән баш тартуга мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләтле орган төзегән ведомствоара комиссиягә шикаять белдерелергә мөмкин.

Объектларны урнаштыруга рөхсәт бирүдән баш тартуга шулай ук гариза бирүче тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru// адресы буенча урнаштырырга һәм рәсми сайтта урнаштыру юлы белән халыкка җиткерегә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.М. Никифоровка йөкләргә.

Җитәкче О.Н.Павлов